КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«28» февраль 2022 ел. №19-п

Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен
«Теле барның юлы бар» - «Знание языка открывает возможности»
республика журналистлар конкурсын үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары белән расланган «2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында боерам:

1. Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Теле барның юлы бар» - «Знание языка открывает возможности» республика журналистлар конкурсы турында кушымта итеп бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының «Теле барның бар» интернет-массакүләм мәгълүмат чаралары өчен Республика журналистлар конкурсын уздыру турында» 2021 елның 28 июньдәге 93-п номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары И.Ф.Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче А.С.Сәлимгәрәев

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының
2022 елның «28» февраль_19-п_ номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Теле барның юлы бар» - «Знание языка открывает возможности» республика журналистлар конкурсын үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Теле барның юлы бар» - «Знание языка открывает возможности» республика журналистлар конкурсын (алга таба – Конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен, шартларын билгели.

1.2. Конкурсның оештыручысы – «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Оештыручы);

1.3. Конкурс агымдагы елның 31 декабренә кадәр үткәрелә уздырыла.

Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүмат Конкурсны оештыручының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) «Яңалыклар», «Конкурслар» бүлекләрендә урнаштырыла. Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүматта конкурс уздыру шартлары, номинацияләр, конкурс эшләрен бәяләү критерийлары һәм тәртибе, заявкаларны кабул итә башлау һәм тәгәлләү вакыты, аларны тапшыру тәртибе, бүләкләү күләме һәм рәвеше, шулай ук Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү тәртибе һәм сроклары күрсәтелә.

## 2. Конкурсның максаты

2.1. Конкурсның төп максаты – Интернет челтәрендә телләрне, гореф-гадәтләрне һәм мәдәниятләрне саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән проектларны гамәлгә ашыручы журналистларны һәм массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләрен ачыклау һәм бүләкләү.

## 3. Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр

3.1. Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары – челтәр басма, басма вакытлы матбугатның, телеканалның, радиоканалның, телепрограмманың, радиопрограмманың, видеопрограмманың, кино хроникасы программасының, даими исем белән тарала торган башка массакүләм мәгълүматның интернет версиясе һәм (яисә) аларның социаль челтәрләрдәге проектлары.

3.2. Гариза бирүче – законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә документлар тапшырган автор яисә авторлар

коллективы, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре тора (алга таба - мөрәҗәгать итүчеләр).

3.3. Катнашучылар - Конкурста катнашуга кертелгән мөрәҗәгать итүчеләр (алга таба - катнашучылар).

3.4. Конкурс комиссиясе – Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары проектларын бәяләүче затлар төркеме.

3.5. Конкурста җиңүче – призлы урын алган катнашучы.

## 4. Конкурста катнашучылар

4.1. Конкурста катнашу өчен гариза бирүчеләр Конкурсны оештыручыга әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә бәян ителгән тәртиптә һәм шартларда гариза тапшырырга тиеш.

## 5. Конкурсны үткәрү тәртибе һәм шартлары

5.1. Гариза түбәндәге документлардан гыйбарәт була:

1) катнашу өчен анкета-гариза (1 нче кушымта) (төп нөсхә, күчермә яисә сканер аша чыгарылган PDF-файл форматындагы вариант);

2) юридик зат буларак теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН) (күчермәсе);

массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турында таныклык (күчермә) яисә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләп кую турында боерык (күчермәсе);

гамәлгә кую документлары (күчермәсе);

3) юридик зат булмаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

ММЧ теркәү турында таныклык яисә Теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә (күчермәсе);

массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе уставы яисә, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясендә кимендә 10 кеше эшләсә, «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – ММЧ турында Закон) 20 статьясы нигезендә аны алмаштыра торган шартнамә күчермәсе;

баш мөхәррирне вазыйфага билгеләп кую турында документның күчермәсе.

4) физик затлар өчен (авторлар, авторлар коллективлары):

шәхесне таныклаучы документ (күчермәсе);

персональ белешмәләрне эшкәртүгә, тапшыруга ризалык (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада бирелгән рәвештә);

персональ белешмәләр субъекты рөхсәт иткән персональ белешмәләрне таратуга ризалык (3 нче кушымта);

Интернет-массакүләм мәгълүмат чараларында уртак проект биргән автор коллективлары яки ММЧ редакцияләре призлы урын бирелгән очракта акчаларны процент нисбәтендә бүлү турындагы килешүне өстәмә рәвештә тәкъдим итә.

5.2. Документлар internet-smi2022@mail.ru электрон адресына яисә түбәндәге адреска җибәрелә: 420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, 6 кат, 608 кабинет, ММЧ бүлеге, «Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган республика журналистлар конкурсына» дигән тамга белән, тел.: 8 (843) 570-31-12.

5.3. Конкурсны оештыручы Гариза бирүчегә конкурста катнашырга түбәндәге очракларда рөхсәт итми:

гаризаның әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында билгеләнгән таләпкә туры килми яисә әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында каралган документлар гаризасына тапшырмый (тулы күләмдә тапшырмый);

гаризада дөрес булмаган белешмәләр булу;

искерүгә яки югалтуга китерә торган дефектлары булган электрон чыганакта гариза бирү.

5.4. Катнашучыга Конкурска кертелмәү турында хәбәр документларны алган мизгелдән алып 3 эш көне дәвамында Оештыручы җитәкчесе/җитәкче урынбасары имзалаган һәм анкета-гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы рәсми хат белән хәбәр ителә.

5.5. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һ.б.) Гариза бирүче тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

5.6. Конкурс шартлары буенча, тәкъдим ителгән эшләрне катнашучыларга кире кайтару, конкурста катнашучының эшне кире кайтару турындагы таләбе буенча гына, мондый таләп алынган мизгелдән алып 20 (егерме) календарь көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

## 6. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

6.1. Сайтлар һәм социаль челтәрләр өчен проектлар түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

контент (сыйфатлы, актуаль булуы) – (0-5 балл);

статистика (аудиторияне җәлеп итү, элемтә урнаштыру) – (0-5 балл);

- стилистика (дизайн, материалны тәкъдим итү ысулы, стиль) – (0-5 балл).

6.2. Конкурс комиссиясе эшкә гомуми баллны конкурс эшләренә комиссиянең барлык әгъзалары куйган бәядән чыгып билгели.

## 7. Конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе

7.1. Конкурс комиссиясенең составы Конкурсны оештыручы боерыгы белән раслана, 5 әгъзадан тора, аларга рәис, рәис урынбасары һәм әгъзалар керә.

7.2. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез башкара.

7.3. Конкурс комиссиясенең эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Утырышта комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип танылa.

7.4. Конкурс эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары аның урынбасарына йөкләнә, урынбасар рәис тарафыннан билгеләнә.

7.5. Әлеге Нигезләмәнең 6 бүлегендә билгеләнгән Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары нигезендә конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы проектларны (һәрбер критерий буенча) 5 баллы система буенча бәяли;

7.6. Конкурска бер генә заявка да бирелмәгән, тапшырылган гаризаларның берсе дә Конкурс шартларына туры килмәсә, катнашкан эшләрнең берсе дә билгеләп үтәргә лаек дип танылмаса, Конкурс үткәрелмәгән дип танылa.

7.7. Һәр критерий буенча баллар суммасы буенча конкурс комиссиясе конкурста катнашучылар рейтингын формалаштыра. Рейтинг нигезендә конкурс комиссиясе конкурста җиңүчеләр исемлеген төзи.

7.8. Иң күп балл җыйган берничә катнашучы булганда, җиңүче тавыш бирү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Җыелган тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче тавыш хәлиткеч булып тора.

7.9. Бүләкләү урыны бирелгән проект автор коллективы тарафыннан башкарылган очракта, әлеге призлы урын өчен билгеләнгән премиягә бүлеп бирелгән акчалар автор коллективы арасында төзелгән килешү нигезендә, конкурс комиссиясенә гариза белән бергә тапшырыла торган килешү нигезендә оешма тарафыннан бүленә.

7.10. Конкурсны оештыручы оештыру-техник эшчәнлекне җайга салу, утырышларны әзерләү һәм конкурс комиссиясе документациясен алып бару өчен җаваплы секретарь билгеләп куя.

7.11. Җаваплы секретарь конкурс комиссиясе составына керми.

7.12. Конкурс комиссиясе утырышы уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә Конкурс комиссиясе утырышы йомгаклары буенча беркетмә рәсмиләштерелә, аңа утырышта булган конкурс комиссиясе әгъзаларының имзасы салына, беркетмә конкурс комиссиясе рәисе яисә рәисе урынбасары тарафыннан раслана.

## 8. Финанс белән тәэмин итү

8.1. Конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле финанс чыгымнары Оештыручыга Конкурсны үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетында «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында тиешле ел өчен каралган акчалар исәбеннән финанслана.

8.2. Гомуми приз фонды 140 000 сум тәшкил итә;

8.3. Конкурста җиңүчеләр акчалата премияләр һәм дипломнар белән түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

I урын – 60,0 мең сум;

II урын – 45,0 мең сум;

III урын – 35,0 мең сум.

8.4. Юридик затларга акчалата премияләр Оештыручының хатында күрсәтелгән кредит оешмасының счетларына акчаларны күчерү юлы белән, җиңүчеләрне игълан иткәннән соң, Конкурска йомгак ясау турындагы беркетмәгә кул куелган көннән башлап, календарь көннәрдә исәпләнә торган 20 көн эчендә түләнә.

8.5. Физик затларга акчалата премияләр Оештыручыга хатында күрсәтелгән банк счетларына акчалар күчерү юлы белән түләнә, җиңүчеләрне игълан иткәннән соң яисә Агентлыкның финанс бүлегендә 20 көн эчендә, Конкурска йомгак ясау турындагы беркетмәгә кул куелган көннән алып календарь көннәрдә исәпләнә торган акчалар акчалар белән бирелә.

8.6. Җиңүчеләрне бүләкләү датасы һәм урыны Оештыручының рәсми сайтында өстәмә рәвештә игълан ителә.

## 9. Аерым шартлар

9.1. Оештыручы түбәндәгеләргә хокуклы:

әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән очраклардан, шулай ук бәхәсле очраклардан тыш, Конкурста катнашучылар белән язмача йә башка төрле элемтәләргә кермәскә;

эшләрне тапшыру срогының беренче яртысында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, Конкурсны туктатырга яки әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, бу хакта Оештыручының рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) «Яңалыклар» һәм «Конкурслар һәм проектлар» бүлекләрендә тиешле мәгълүмат урнаштырып, Катнашучыларга хәбәр итәргә.

«Татмедиа» республика матбугат
һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгының
2022 елның «28» _февраль_19-п
номерлы боерыгы белән
расланган Интернет массакүләм
мәгълүмат чаралары өчен
«Теле барның юлы бар» -
«Знание языка открывает
возможности»
республика журналистлар
конкурсын үткәрү турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта

| Конкурста катнашу өчен анкета-гариза | |
|---|---|
| Интернет-проектның исеме | |
| Проект урнаштырылган интернет-ММЧ исеме | |
| Проектны кыскача тасвирлау | |
| Проект битенә актив сылтама | |
| Проектның актуаль булуы (хәзерге вәзгыятьтә проектның мөһимлеге) | |
| Проектның максатлары һәм бурычлары | |
| Интернет-ММЧ җитәкчесе | |
| Элемтәләр (телефон, e-mail) | |
| Катнашучының шәһәре/ торак пункты | |

______________________________________________

**(интернет-ММЧ хуҗасының имзасы, фамилиясе, булган очракта, мөһер)**

«Татмедиа» республика
матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгының
2022 елның «28» февраль 19-п
номерлы боерыгы белән
расланган
Интернет массакүләм мәгълүмат
чаралары өчен
«Теле барның юлы бар» -
«Знание языка открывает
возможности»
республика журналистлар
конкурсын үткәрү турында
нигезләмәгә
2 нче кушымта

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,_______________________________________________________________,
яшәү адресым_______________________________________________
__________________________________________________________________________,
шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)______________________
__________________________________________________________________________
__________________________________, "Персональ белешмәләр турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә "Татмедиа" республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420097, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Теле барның юлы бар» - «Знание языка открывает возможности» республика журналистлар конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.
Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге: | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр) |

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

_______________________________________________________________/______________

(персональ белешмәләр субъектының Ф.И.Ат ис. (булган очракта күрсәтелә) һәм имзасы)

_______________

(Дата)

«Татмедиа» республика матбугат
һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгының
2022 елның «28» февраль_19-п
номерлы боерыгы белән
расланган Интернет массакүләм
мәгълүмат чаралары өчен
«Теле барның юлы бар» -
«Знание языка открывает
возможности»
республика журналистлар
конкурсын үткәрү турында
нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин, ___________________________________________________________________________,
(фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта) рус телендә)
______________________________________________________________________________,
(почта адресы)
______________________________________________________________________________,
(электрон почта адресы)
______________________________________________________________________________,
(телефон номеры)

“Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган республика журналистлар конкурсын оештыручы “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (ОГРН 1031621014765, ОКТМО 92701000, ОКПО 14912163) юридик адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Теле барның юлы бар» - «Знание языка открывает возможности» республика журналистлар конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне таратуга (шул исәптән башкаларга тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | Әйе | ЮК |
| Гомуми персональ белешмәләр | | | |
| | Фамилия | | |
| | Исем | | |
| | Атасы исеме (булган очракта) | | |
| | Туган ел, ай, дата һәм урын | | |
| | Адрес | | |
| | Белем | | |
| | Һөнәр | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. [Персональ белешмәләрнең категориясе] | | |
| | [Персональ белешмәләрнең исемлеге] | |

Искәрмә. Күрсәтелгән таблица персональ белешмәләр субъектының теләге буенча, персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан чикләүләрсез тутырыла.
Шартлар һәм тыюлар операторның чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына әлеге персональ белешмәләрне таратуга һәм (яисә) тапшыруга бәйле гамәлләрен чикләүне йә тыюны күздә тота.
Ризалыкта өстәмә шартлар да күрсәтелергә мөмкин, алар алынган персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан мәгълүмат кайбер хезмәткәрләргә генә җиткерелә торган эчке элемтәләр буенча йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша тапшыруны, яки алынган персональ белешмәләрне тапшырмауны күздә тота

Операторның персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына тапшырылырга мөмкин мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://tatmedia.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык ______________________________ срокта гамәлдә була.

(ризалыкның гамәлдә булу срогы)

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тартырга хокуклы.
Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тарткан очракта оператор мондый баш тартуны алган көннән алып иң күбе утыз көн эчендә аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм, элек куелган максатлар өчен персональ белешмәләрне эшкәртү башкача таләп ителмәсә, персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) тиеш.
Күрсәтелгән срокта персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый персональ белешмәләрне блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм персональ белешмәләрне алты айдан артмаган срокта юкка чыгаруны тәэмин итә.

_____________( персональ белешмәләр субъекты имзасы)
_____________ (число, ай, ел)